ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА МЕНЗЕЛИНСКА
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МИНЗӘЛӘ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
от 05. 09. 2025

КАРАР
№ 422

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының
"Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Производственная урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:28:180101:1 булган, мәйданы 13234 кв.м. җир участогының шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрен бирү турында - Минзәлә муниципаль районының "Минзәлә шәһәре" муниципаль берәмлеге җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча житештерү зонасында (ПК) "складлар" өчен" боерыгы проекты буенча ачык тыңлауларны билгеләү турында

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына, Россия Федерациясенең 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законына, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына ярашлы, Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Минзәлә шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының "Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, Производственная урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан, мәйданы 13234 кв.м. булган, кадастр номеры 16:28:180101:1 җир участогын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турында" боерыгы проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларны оештыручы составын - коллегиаль киңәшмә органын расларга:

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Чухланцев Д.А.;

Минзәлә муниципаль районының "ПИЗО" МКУ рәисе Шакиров Р.С.;

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы урынбасары - баш архитектор Петров В.К.

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетынын төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы Басков Е. А.,

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Советының юридик сектор мөдире Петрова А.В.

3. Ачык тыңлауларны оештыручыга ачык тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм

уздыруны тәэмин итәргә.

4. Ачык тыңлаулар үткәрү чорын билгеләү – 2025 елның 15 сентябреннән 2025 елның 26 сентябренә кадәр. Ачык тыңлаулар 2025 елның 30 сентябренә кадәр үткәреләчәк.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Шәйсуваров